СОВЕТ МУРАЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МӨРӘЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

12.10.2015 ел. Мөрәле ав. № 6

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Мөрәле авыл җирлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2014 елның 19 ноябрендәге 34 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексының 5 статьясының 3 һәм 4 пункты, Кайбыч муниципаль районы Мөрәле авыл җирлеге Уставының 5 ст. 1 өлешенең 2 пункты, 4 пункты, 31 статьясы нигезендә Кайбыч муниципаль районы Мөрәле авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Мөрәле авыл җирлеге Советының 2014 нче елның 19 ноябрендәге 34 номерлы "Физик затлар мөлкәтенә салым турында " ( 2015 нче елның 15 июнендәге 17 нчы номерлы Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Мөрәле авыл җирлеге Советы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән ) карарына үзгәрешләр кертергә:

- 2 пунктның 4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә :

«4) 2015 елда - 1,2 процент, 2016 елда - 1,5 процент, 2017 елда - 1,8 процент, 2018 елда һәм алдагы елларда-Россия Федерациясе Салым кодексының 378 статьясындагы 2 өлешнең 7 пункты нигезендә билгеләнә торган исемлеккә кертелгән салым салу объектларына карата 2 процент; 378 статьяның икенче өлешендәге 10 пункты нигезендә каралган салым салу объектларына карата Россия Федерациясе Салым кодексы.

Аларның һәрберсе кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып киткән очракта, салым салу объектларына карата 2 процент күләмендә даими кала».

2. Әлеге карарны « Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында »(PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Кайбыч муниципаль районы Мөрәле авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2015 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Мөрәле авыл җирлеге
Башлыгы Р.Р.Зиннәтуллин